# ТОРМЫШКА АШКАН ХЫЯЛ

*Альманах. Искусствоведение Татарстана. «Сәнәигы нәфисә». Выпуск 1. Теория, история, современная художественная практика, арт-рынок. Автор-составитель Р.Р. Султанова. Казань, 2017. 313 с.: ил.*

Сәнгать белеме өлкәсен киң колачлаган махсус җыентыкның дөнья күрүе республикабыз мәдәни тормышына яңа сулыш өрде. Мондый басмалар басылып чыгу яңалык түгел әлбәттә, ә бусы тирән эчтәлекле һәм концепцияләренең гаять киңлеге белән аерылып тора. «Альманах»ның бурычы ватан һәм дөнья сәнгать киңлегендә Татарстан Республикасы сәнгать тормышындагы заманча юнәлешләрне ачыклау гына түгел, ә, Рауза Солтанованың «Редактор сүзе»ндә тәфсилле әйтелгәнчә, сәнгать белеме фәне горизонтларын киңәйтү, яңа идеяләрне, кураторлык проектларын фәнни яктан дөрес бәяли белүне дә үз эченә ала.

Чыннан да, «Альманах» сәнгать белеме өлкәсендәге әлегә кадәр туплаган күнекмәләребезне бөтенләй киңәйтеп җибәрә, төрле юнәлештәге киң катлау белгечләрне фикер алышуга, бәхәсләшүләргә, хәтта тәнкыйди чыгышларга этәрә. Һәм болар барысы да объектив анализлау осталыгын камилләштерергә ярдәм итә, шулай ук арт-концепцияләргә төшенергә һәм сәнгати практикаларга юл ача.

«Альманах»ның әлеге чыгарылышы сәнгать белеме өлкәсендәге күп төрле юнәлешләрне ачыкларга мөмкинлек бирә. Басмада урын алган бүлекләрне атап үтү генә дә аны төзүчеләрнең фикри тирәнлеген дәлилли: әйтик, мирас, иҗади портретлар, сәнгать белеме бирү өлкәләрен җитди өйрәнүдән башлап, яңа басмаларны рецензияләүгә һәм арт-хроникаларга кадәр тематиканы эченә ала. «Альманах»ны горизонталь яссылыклардан торган пирамидаларга тиңләп була: нигезендә – аерым сәнгати катламнар (арт-хроника, күргәзмәләр, пленэрлар, иҗади сәяхәтләр); аннан өстә – «Зур Идел» һәм «Болгарлар. Миф. Чынбарлык» проекты, «Урман-арт» этнофутуристик симпозиум кебек елның үзенчәлекле вакыйгалары. Иҗади портретлар. Юбилярлар. Сәнгатьтә – яшьләр. Дүртенче яссылыкта – Сәнгать белеме бирү. Һәм, ниһаять, пирамиданың иң югары өлешендә – Мирас. Ул бүлектәге Динә Хисамованың «Формирование кадров скульпторов-монументалистов Татарии», Светлана Червоннаяның «Истоки и генезис искусства исламской эпиграфики. Резные надгробия крымских татар» хезмәтләре материалны чыганаклар ярдәмендә тирәнтен өйрәнеп язылганнар. Ольга Улемнова «Татарский левый фронт искусств» өлкәсен, 1920 еллардагы совет сәнгате темасының дәвамы рәвешендә, һәркемне җәлеп итәрлек итеп яктырткан. Николай Фешин иҗаты буенча әйдәп баручы белгеч Галина Тулузакова

күренекле нәкышьче турында күңелләрне күтәреп җибәрердәй мәкалә белән чыгыш ясый, автор мәгълүмати яктан гына түгел, теле-стиле буенча да югары кимәлдә яза белүе белән аерылып тора. Илебездә бүген сәнгать белеме үсеше картинасын Рауза Солтанова, сәнгатне һәм мәдәниятне өйрәнү юнәлешләренең мөһимлегенә басым ясап, кыска гына, әмма оста итеп тасвирлаган.

«Альманах»ның әһәмияте аның сәнгати практикага йогынтысы белән бәяләнә. Татарстанның көньяк-көнчыгыш регионы сәнгать белгечләре һәм гомумән сәнгать сөючеләр җәмәгатьчелеге әлеге басманы рухланып кабул иттеләр. Иҗади интеллигенция вәкилләре өчен үз эшчәнлекләрен Татарстан сәнгатенең бүгенге үсеш дәрәҗәсеннән чыгып бәяләргә, ягъни иҗатыңа тәнкыйть күзлегеннән карап, аны сәнгать белеменә нигезләп, үзеңнең күргәзмәлелек тупламаңны күздән кичереп, яңа оригиналь проектлар эшләргә, күңелеңә якын темаларга башка ракурстан карарга, шулай итеп, иҗади импульсыңны җанландырып җибәрергә мөмкинлек туды. Иҗатчы-рәссам өчен иң мөһиме – әсәрләреңнең чын мәгънәсендәге сәнгать белгечләре тарафыннан анализлануы. Уңай яктан яки реклама характерында гына түгел, ә объектив якын килеп, кирәк икән, конкрет тәкъдимнәр күрсәтелгән анализ ясалу зарур. Бүгенге сәнгать белемендә мондый анализлар онытылды диярлек, чөнки сәнгати концепцияләрнең төрлелеге чиктән ашты, ә аларның гәүдәләнеше сыйфатына карата сүз әйтергә хәзер бөтенләй батырчылык итмиләр. Ә инде яңа «Альманах»та басылган материалларга таянып, сәнгать әсәрләренә тәнкыйди күзлектән чыгып бәя бирүгә, фикерләр каршылыгын ачыктан-ачык белдерүгә юл ачылды. «Зур Идел» («Большая Волга») X һәм XI күргәзмәсенә карата белдерелгән бәяләмәләр һәрчак көнүзәк темаларның берсе булып кала бирә. Владимир Кошаевның күләмле мәкаләсендә 2008 елгы күргәзмәләрнең программа тезислары белән рәсем сәнгатенә карата булган таләпләр һәм тәкъдимнәр тәңгәллеге хакындагы мөһим идеяләр күтәрелә. Автор сәнгатьнең эчтәлеге белән кызыксыну көчәюен билгеләп үтә. Ул гомумсәнгать һәм, аерым алганда, провинциядә яшәп иҗат итүче авторларның күбесе өчен актуаль саналган милли-тарихи бердәмлеккә, Россиядә сәнгатькә караш һәм заманча сәнгати фикерләү проблемаларына киң урын бирә. Ә менә 2013 ел күргәзмәләрен яктыртуга саерак туктала. Бу өлеш, нигездә, анда катнашучылар хакында констатацион характердагы шәрехләмәләрне генә хәтерләтә.

Басманың «Творческие портреты (художник о своем творчестве)» бүлеге сәнгать осталары турында автор поэзиясе – «За кругом бытия» – рәссамнар игътибарын аеруча җәлеп итә. Әлбәттә, алар арасында урын алу өчен үзенчәлекле талантка ия булырга кирәк, ә ул һәркемгә бирелмәгән, әмма андый шәхесләр безнең якларда да бар. «Альманах»ның әһәмияте тагын шунда – аның

аша без рәссамнар гына түгел, ә сәнгать белгечләре һәм сәнгатебезнең тарихчылары хакында да шактый мәгълүмат алдык. Мин үзем, мәсәлән, киң белемле тикшеренүче Динә Вәлиева турындагы мәкаләне бик рәхәтләнеп укыдым. «Альманах»ның алдагы чыгарылышларында әйтеп үтелгән темалар тагын да тирәнрәк күтәреләчәгенә ышанып калабыз. Мондый басманың бурычы да бит мәдәни-сәнгати киңлектәге һәр вакыйганы җәһәтлек белән яктырта бару.

Мәдәният, сәнгать белгечләрен, тарихчыларны, крайны өйрәнүче һәм музей хезмәткәрләрен, галереялар оештыручы һәм педагогларны дисциплинаара фәнни диалогка җәлеп итү максаты белән даими уздырыла торган фәнни-гамәли конференцияләр, беренче чиратта, сәнгать белеме өлкәсендә, республика белгечләреннән тыш, Россиянең төрле регионнары һәм башка илләр сәнгатькәрләрен турыдан-туры актив фикерләүгә тарту өчен оештырыла. Анда күтәрелгән һәр проблеманың һәм аларның чишелеш юлларының «Альманах»ның алдагы чыгышларында яктыртылып баруы зарур.

Сәнгать белеме өлкәсендә күтәрелгән проблемалар, тикшеренү барышында килеп туган оригиналь идеяләр, өйрәнелә торган тема буенча гамәли хезмәткәрләрне генә түгел, регион сәнгате теоретикларын да яңача фикерләүгә этәрергә мөмкин. Мин үзем күп еллар дәвамында Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәгендә сынлы сәнгать үсешенең төп юнәлешләрен ачыклау, ватан һәм дөнья сәнгате үсешенең гомум агымы контекстында аның аерым вәкилләре иҗатын барлау өстендә эшлим. Ә инде «Альманах»ның әлеге басмасы белән танышып чыгу миңа башлаган эшемне дөрес планлаштырып алып барырга ярдәм итте, аның файдасызга югалып әрәм булмасына ышанычым артты.

Басманың авторлар коллективы искиткеч зур һәм профессиональ яктан югары дәрәҗәдәге эш башкарган. Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәгендә сәнгати эшчәнлек алып барган барлык хезмәттәшләрем исеменнән шушы «Альманах»ны төзеп-туплап чыгаручы иҗади коллективны чын күңелдән котлыйм. Менә дигән белгеч, сәнгать өлкәсендә гадәттән тыш актив эш алып баручы Рауза Солтановага аеруча рәхмәтлебез. Ул, әлеге басманың һәм башка күп кенә проектларның фәнни җитәкчесе һәм авторы, республика сәнгать тормышын җанландыруга зур көч кую белән бергә, үзенең фикердәшләрен иҗади эшкә рухландыручы да.

«Альманах» басмаларын туплап чыгару дәвам итәчәгенә, аның һәр санына ихтыяҗның зур булачагына ышанычыбыз зур.

***Горюнова Нина Михайловна,***
*сәнгать белгече, Лениногорск музыкаль сәнгать-педагогика көллияте укытучысы*